Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 27 ноябре № 56/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 34/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» 2023 елның 10 февралендәге 34/1 номерлы Чистай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 9 пунктында:

1.1.1. 6 пунктчада «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле яңа 9 пунктча өстәргә:

«9) бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгели.».

1.2. 5.1 статьяда:

1.2.1. 10 пунктта «242_25 һәм 242_26 статьялары белән» сүзләрен «24_4 бүлеге белән» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2.2. 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актында билгеләнгән очракларда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә җирлекнең финанс органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_26 статьясының 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән акчаларны киңәйтелгән казначылык озатып йөрүен гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

1.3. 38 статьяда:

1.3.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«-бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

1.3.2. 3 пунктның соңгы абзацында «норматив йөкләмәләрне» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 7 пунктының егерме бишенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы В.Л. Донеев